# Минем яраткан спортчым - Нурмөхәммәт Алимов «Кара Малай»



Язды 71101 группа
студенты Гирфанова Алсу




Нурмөхәммәт Нивман улы Алимов 1892 елда Мәскәү шәһәрендә ярлы эшчеләр гаиләсендә туган. Аның әтисе йөк ташучы, әнисе – тукучы булган.

Гаиләдә акча җитмәгәнлектән Нурмөхәммәт Алимов мәктәпкә укырга йөри алмый, ул ун яшеннән бай сәүдәгәрләргә ялланып эшли башлый.

Кечкенәдән урамда кул – йодрык сугышларында катнашып үсә.




Россиянең танылган боксчылары: 1-Э.И.Лусталло, 2-В.М.Жуков, 3-И.Б.Граве, 4-А.Г.Харлампиев, 5-Н.Н.Алимов (Кара Малай), 6-П.В.Никифоров, 7-В.В.Самойлов.

1911 елда тренер Владимир Михайлович Жуков Нурмөхәммәтне инглиз боксы түгәрәгенә чакыра.

Шул ук елны Нурмөхәммәт беренче тапкыр Мәскәүдә уздырылган халыкара бокс көрәшендә катнаша һәм бик зур уңышларга ирешә.

Кара куе чәче һәм тән тиресе өчен аңа “Кара Малай” кушаматын тагалар.



1913 елда “Санитас” бокс клубы барлыкка килә. Нурмөхәммәт шушы спорт клубында танылган спортчы булып үсә, 18 яшендә укырга һәм язарга өйрәнә.

1914 елда Алимов Петроград шәһәрендә чемпион исемен яклый.

1915 елда Мәскәү, Россиянең абсолют чемпионы исеменә лаеклы була.




1915 елда Алимовны патша армиясенә хәрби хезмәткә алалар. Ул анда солдатларны көрәш серләренә өйрәтә, разведчиклар әзерли.

1917 елда ул Кызыл Армия составында гражданнар сугышында актив катнаша. Беренче мөселманнар полкының командиры була.




1935 елда Нурмөхәммәт Алимов (Кара Малай) легендар «Спартак» футбол җәмгыятенә нигез сала.

РСФСР ның бокс Федерациясен җитәкли һәм бик күп еллар Бөтенсоюз бокс секциясенең әгъзасысы булып илгә хезмәт күрсәтә.




Лаеклы ялга чыккач, бик күп еллар балалар тренеры булып эшли, яшьүсмерләргә бокс серләрен өйрәтә.



Нурмөхәммәт Алимов гомере буе яшьләрне спорт белән шөгыльләнергә өндәп, спортка мәһәббәт тәрбияләп яшәде.

Ул халыкка күрсәткән хезмәте, спортка булган хөрмәте өчен дәүләт тарафыннан Кызыл Байрак ордены белән тәбрикләнде.

Бөек боксчы 1964 елны вафат булды.




Танылган татар егете Нурмөхәммәт Алимов турында Рәмзи Һиләлов 1984 елда “ Батыр уходит в легенду” исемендә китап бастытырып чыгарды.

Минем иң изге теләгем шундый биек спортчыларны зурлап онытмыйча яшәргә иде.